| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ ЮЛБАТСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САБИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САБА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЮЛБАТ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| 422077, Республика Татарстан,<br>с. Юлбат, ул. Г.Тукая, 57<br>тел. (84362) 43-7-22 | 422077, Татарстан Республикасы,<br>Юлбат авылы, Г.Тукай урамы, 57 йорт<br>тел. (84362) 43-7-22 |

e-mail: Ulbat.Sab@tatar.ru

13.11.2024 № 26

РЕШЕНИЕ КАРАР

Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советының 28.04.2018 №11 «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» карарына үзгәрешләр кертү турында

Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 25.09.2024 елгы №829 «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 елгы №182 «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр органнары, муниципаль хезмәткәрләр хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының һәм муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында Нигезләмә» нең 28.04.2018 елгы №11 карарына (Советның 09.11.2020 №13, 17.10.2022 №16, 19.12.2022 №23, 26.08.2024 №15 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладын 13 990 сум күләмендә расларга.»;

1.2. Карарга 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге үзидарә органнарына әлеге карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кергән яңа штат расписаниеләрен расларга.

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ulbat адресы буенча урнаштырырга.

Юлбат авыл җирлеге Башлыгы Т.Р.Шәмсиев

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Юлбат авыл җирлеге
Советының 13.11.2024 №26 карарына
1 нче кушымта

Саба муниципаль районы Юлбат авыл җирлеге Башлыгының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручыга акчалата бүләк күләме

| Вазыйфаларның исеме | Акчалата бүләк күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Авыл җирлеге Башлыгы | 19173 |
| Депутатлар | 13990 |
| Сайланулы вазыйфаи затлар | 13990 |